**Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Вязовка авыл җирлеге составына керүче Коногоровка авылы торак пунктында гражданнар җыены карары**

**2023 елның 24 ноябре, № 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Вязовский авыл җирлегенең Коногоровка авылы торак пунктында гражданнар җыены

Карар кабул итте:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Вязовка авыл җирлегенең Коногоровка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучыларыннан, тыл хезмәтчәннәреннән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, гражданнарның үзара салымы 1000 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны Коногоровка авылындагы зиратны төзекләндерүгә юнәлтергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Вязовский авыл җирлеге башлыгы А. Г. Томский**